КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 декабрь г.Казань № 1307

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендәге мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү кыйммәте нормативларын һәм эш режимы 12 сәгать булган каравыл постлары санын билгеләү турында» 2021 ел, 24 ноябрь, 1114 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендәге мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү кыйммәте нормативларын һәм эш режимы 12 сәгать булган каравыл постлары санын билгеләү турында» 2021 ел, 24 ноябрь, 1114 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хосусый каравыл оешмаларыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары объектларының (территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны гамәлгә ашырганда әлеге хезмәт күрсәтүләр кыйммәте нормативларын һәм 12 сәгатьлек эш режимы белән каравыл постлары санын билгеләү турында»;

1 пунктның беренче абзацын татар текстында түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Хосусый каравыл оешмаларыннан Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары (алга таба – мәгариф оешмасы) объектларының

(территорияләренең) террорчылыктан сакланышын тәэмин итүгә бәйле хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны гамәлгә ашырганда әлеге хезмәт күрсәтүләр кыйммәте нормативларын түбәндәгечә билгеләргә:».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин